## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
## Иске Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

**№ 7**

**05 апрель 2016 года**

**Мәҗбүри эшләр рәвешендә җәзаны үтәргә хөкем ителгән затларның җәзаны үтәү урыннарын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы президиумының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эшләр төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында " 2012 елның 8 июнендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларның нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалыхезмәткә, административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә. һәм судның законлы көченә кергән карары буенча административ җәзаны үтәү рәвешендә башкарыла торган мәҗбүри эшләр мәҗбүри хезмәт дип саналуын исәпкә алып. Иске Ибрай авыл җирлегебашкарма комитеты

Карар кабул итте:

1. Иске Ибрай авыл җирлеге территориясе чикләрендә мәҗбүри эшләрне башкару урыннарын билгеләргә: Иске Ибрай торак пунктында җинаять – башкару инспекцияләре белән килешүбуенча.

2. Мәҗбүри эштөрләрен билгеләргә – торак пунктларны төзекләндерү һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, юллар һәм буалар буендагы куакларны кисү, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, җинаять-башкару инспекцияләре белән килешү буенча юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Аксубай районы буенча ФКУ филиалы беләнберлектә Россия Федераль җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе җинаять-башкару инспекциясет арафыннан Иске Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм төзәтү яки мәҗбүри эшләргә хөкем ителгән затларга карата суд хөкемнәрен үтәүне тәэмин итү өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны Иске Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: http:// aksubayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе М. Г. Миңнегулов